ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
26.12.2024

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
№ 5414

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 29 апрелендәге «Җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен уздыруга проект документациясен килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 1049 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибе, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 29 апрелендәге«Җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен үткәрүгә проект документациясен килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 1049 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.3.2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3.2. Техник мөмкинлек булганда Регламентның 3.3.3.1 пунктында күрсәтелгән процедураларны башкару, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматик режимда гамәлгә ашырыла

Регламентның 3.3.3.1 пунктында күрсәтелгән, һәм шул исәптән пространство мәгълүматларыннан файдалануга бәйле аерым процедураларны башкару кысаларында, пространство мәгълүматларының милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә».

1.2. 3.4.4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.4.4. Техник мөмкинлек булганда Регламентның 3.4.1, 3.4.3 пунктларында күрсәтелгән процедуралар, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланып, автомат режимда, шул исәптән гаризаны Регламентның 2.13 пункты нигезендә теркәү вакытыннан алып башкарыла.

Регламентның 3.4.1, 3.4.2 пунктларында күрсәтелгән һәм пространство мәгълүматларыннан файдалануга бәйле аерым процедураларны башкару кысаларында, пространство мәгълүматларының милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә ».

1.3. 3.5.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.4. Техник мөмкинлек булганда Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны башкару, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматик режимда гамәлгә ашырыла

Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән пространство мәгълүматларыннан файдалануга бәйле аерым процедураларны башкару кысаларында, пространство мәгълүматларының милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә».

1.4. 3.6.1. пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.6.1. Административ процедураны башкару өчен нигез булып административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүне кире кагуны) раслый торган документны алуы тора.

Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи зат булып - *вазифаи зат турында белешмәләр* (7 нче кушымта) (алга таба - документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазифаи зат)тора.

Документларны бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазифаи зат:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасының документлар белән эшләү буенча ярдәмче системасында һәм (яки) шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләрне теркәүне һәм кертүне тәэмин итә;

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) Республика порталы аша электрон хезмәттәшлек ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен күпфункцияле үзәктә алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Техник мөмкинлек булганда процедураларны башкару, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда башкарыла.

Процедураларны башкару кысаларында, шул исәптән пространство мәгълүматларыннан файдалануга бәйле пространство мәгълүматларының милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүне кире кагуны) раслый торган документ имзаланган көнне Башкарма комитетның вәкаләтле вазифаи заты (Башкарма комитет) тарафыннан башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүмат системаларында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә белешмәләр урнаштыру, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү».

2. Административ регламентны түбәндәге эчтәлектәге 4.5 пункт белән тулыландырырга: «Үз функцияләрен тәэмин итү өчен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системаларын, шулай ук пространство мәгълүматларының милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын файдаланырга» .

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Зеленодольск муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин